# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Габдрахман авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**17.11.2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 17.11.2023 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде киләсе сорау буенча «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә сез ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Абдрахман торак пунктында һәлак булган сугышчыларга һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, мемориаль плитәләр сатып алу һәм урнаштыру, буяу, пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү);

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Абдрахман торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (керү төркемен төзү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү), чишмәгә юлны ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 27 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

ризалык позиция өчен гражданнар җыенында катнашучы 20 кеше тавыш бирде;
каршы позиция өчен 0 тавыш.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пунктында гражданнар җыены узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.

2. Киләсе сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә сез ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Абдрахман торак пунктында һәлак булган сугышчыларга һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, мемориаль плитәләр сатып алу һәм урнаштыру, буяу, пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү);

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Абдрахман торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (керү төркемен төзү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү), чишмәгә юлны ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)».

3. Сарман муниципаль районының Габдрахман авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов